ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.10.2016 Казан ш. № 10-14/кс

«Алабуга җылылык челтәрләре предприятиесы» ачык акционерлар җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифны билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Алабуга җылылык челтәрләре предприятиесы» ачык акционерлар җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифларны әлеге карар кушымтасы нигезендә билгеләргә

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карарның үз көченә кергән көннән алып 2016 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Алабуга җылылык челтәрләре предприятиесы» ачык акционерлар җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы айга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазифаларын башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
18.10.2016 № 10-14/кс
карарына кушымта

## «Алабуга җылылык челтәрләре предприятиесы» ачык акционерлар җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, кайнар су белән тәэмин итүче оешма атамасы | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тариф (ике компонентлы) | |
|---|---|---|---|
| | | Салкын суга компонент, сум/куб.м | Җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал |
| | | карарның үз көченә кергән көннән алып 31.12.2016 кадәр | карарның үз көченә кергән көннән алып 31.12.2016 кадәр |
| | Алабуга муниципаль районы | | |
| 1 | «Алабуга җылылык челтәрләре предприятиесы» ачык акционерлар җәмгыяте | | |
| | Тарловка авылы кулланучылары | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДС белән күрсәтелгән)* | 22,01 | 1905,11 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | 18,65 | 1614,50 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәсе 6 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан чыгып бүлеп бирелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге